**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью 12 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении условий реализации прав граждан на проведение собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2019 года

**Статья 1**

Внести в статью 12 Закона Республики Татарстан от 25 декабря 2012 года № 91-ЗРТ «Об обеспечении условий реализации прав граждан на проведение собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 12 (II часть); 2014, № 7; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«Статья 12. **Места, в которых запрещается проведение публичных мероприятий**

В соответствии с частью $2^2$ статьи 8 Федерального закона в случае, если проведение публичных мероприятий может повлечь нарушение прав и свобод человека и гражданина, законности, правопорядка, общественной безопасности, в том числе нарушение функционирования объектов жизнеобеспечения, транспортной или социальной инфраструктуры, связи, создать помехи движению пешеходов и (или) транспортных средств либо доступу граждан к жилым помещениям или объектам транспортной или социальной инфраструктуры, проведение собраний, митингов, шествий, демонстраций запрещается в следующих местах:

1) на территориях, прилегающих к объектам жизнеобеспечения, военным объектам, а также к зданиям, отнесенным в порядке, установленном Правительством Российской Федерации в соответствии с Федеральным законом от 6 марта 2006 года № 35-ФЗ «О противодействии терроризму», к местам массового пребывания людей в целях обеспечения их антитеррористической защищенности;

2) на территориях, прилегающих к железнодорожным вокзалам и платформам, автобусным и речным вокзалам, аэропортам, объектам метрополитена, связи, остановкам маршрутных транспортных средств;

3) на территориях, прилегающих к образовательным, медицинским, физкультурно-оздоровительным, спортивным организациям, организациям социального обслуживания, культуры, отдыха детей и молодежи, к культовым сооружениям;

4) на территориях стоянок (парковок) транспортных средств;

5) на территориях, предназначенных и приспособленных для отдыха несовершеннолетних и инвалидов.

Оценка угрозы нарушения прав и свобод человека и гражданина, законности, правопорядка, общественной безопасности, в том числе нарушения функционирования объектов жизнеобеспечения, транспортной или социальной инфраструктуры, связи, создания помех движению пешеходов и (или) транспортных средств либо доступу граждан к жилым помещениям или объектам транспортной или социальной инфраструктуры осуществляется уполномоченным органом с учетом специфики конкретного публичного мероприятия исходя из его целей и вида (характера), предполагаемого количества участников, даты проведения, времени начала и окончания, места проведения, а также иных обстоятельств.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
25 декабря 2019 года
№ 111-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12 статья. **Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар**

Федераль законның 8 статьясының $2^2$ өлеше нигезендә, гавами чаралар уздыру кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген бозуга, шул исәптән яшәеш тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлеген бозуга китерсә, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына тоткарлык тудырса, җыелышларны, митингларны, урам йөрешләрен, демонстрацияләрне түбәндәге урыннарда уздыру тыела:

1) яшәеш тәэмин итү объектлары, хәрби объектлар янәшәсендәге территорияләрдә, шулай ук «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә халыкның террорчылыктан саклануын

тәэмин итү максатында күпләп җыелу урыннарына карый торган биналар янәшәсендәге территорияләрдә;

2) тимер юл вокзаллары һәм платформалары, автобус һәм елга вокзаллары, аэропортлар, метрополитен, элемтә объектлары, маршрут транспорт чаралары тукталышлары янәшәсендәге территорияләрдә;

3) мәгариф, медицина, физкультура-савыктыру, спорт оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү, мәдәният, балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмалары, гыйбадәтханә корылмалары янәшәсендәге территорияләрдә;

4) транспорт чараларын кую урыннары (парковкалар) территорияләрендә;

5) балигъ булмаганнар һәм инвалидлар ялы өчен каралган һәм җиһазландырылган территорияләрдә.

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, законлылык, хокук тәртибе, җәмәгать иминлеге бозылу, шул исәптән яшәеш тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлеге бозылу куркынычын бәяләү, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарга яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына тоткарлык тууны бәяләү, конкрет гавами чараның үзенчәлеген исәпкә алып, аның максатлары һәм төреннән (характерыннан), анда катнашучыларның фаразланган саныннан, уздыру датасыннан, башлану һәм төгәлләнү вакытыннан, уздыру урыныннан, шулай ук башка билгеләреннән чыгып, вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 111-ТРЗ